**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Яңа Элмәле авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 27 октябрендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында**

18 март 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары (2023 елның 29 ноябрендәге №1532 редакциясендә) белән расланган үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыенына түбәндәге мәсьәлә чыгарылды:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 27 октябрендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү белән һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдировкалау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Яңа Элмәле торак пунктында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, җиңел автомобильгә прицеп сатып алу, агачларны кисү, хезмәт хакы түләү һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле кораллар һәм материаллар сатып алу; генератор сатып алу;

**- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (Яңа Элмәле торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алыштыру);

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (тәгәрмәчләрдә янгынга каршы савыт сатып алу; мотопомпа сатып алу);

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (Яңа Элмәле торак пунктында урам-юл челтәрен салу өчен вак таш сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу).

**Гражданнар җыены карар кылды:**

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында халык җыены **булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.**

3. Киләсе карарны: «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 3 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 27 октябрендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Яңа Элмәле торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында» түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә:

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдировкалау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Яңа Элмәле торак пунктында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, җиңел автомобильгә прицеп сатып алу, агачларны кисү, хезмәт хакы түләү һәм югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле кораллар һәм материаллар сатып алу; генератор сатып алу;

**- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны**

**гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (Яңа Элмәле торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алыштыру);

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (тәгәрмәчләрдә янгынга каршы савыт сатып алу; мотопомпа сатып алу);

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (Яңа Элмәле торак пунктында урам-юл челтәрен салу өчен вак таш сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу) **кабул ителгән дип танырга.**

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы И.М.Җамалтдинов